КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 5 ноябрь г.Казань № 999

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 ел, 17 декабрь, 542 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 22 гыйнвар, 22 нче; 2005 ел, 30 май, 239 нчы; 2006 ел, 2 октябрь, 490 нчы; 2007 ел, 6 апрель, 123 нче; 2008 ел, 8 сентябрь, 640 нчы; 2010 ел, 29 ноябрь, 956 нчы; 2011 ел, 21 июнь, 496 нчы; 2011 ел, 6 декабрь, 1001 нче; 2012 ел, 13 апрель, 304 нче; 2013 ел, 19 гыйнвар, 20 нче; 2013 ел, 12 март, 157 нче; 2014 ел, 8 февраль, 80 нче; 2014 ел, 5 декабрь, 947 нче; 2015 ел, 15 апрель, 254 нче; 2015 ел, 1 декабрь, 911 нче; 2016 ел, 22 июнь, 425 нче; 2016 ел, 10 сентябрь, 625 нче; 2016 ел, 20 декабрь, 959 нчы; 2017 ел, 10 май, 268 нче; 2017 ел, 28 август, 604 нче; 2017 ел, 27 октябрь, 812 нче; 2017 ел, 1 ноябрь, 833 нче; 2018 ел, 25 декабрь, 1228 нче; 2019 ел, 7 март, 163 нче; 2019 ел, 5 август, 644 нче; 2019 ел, 10 декабрь, 1131 нче; 2020 ел, 2 июнь, 461 нче; 2020 ел, 11 сентябрь, 827 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.2 нче пунктның бишенче һәм алтынчы абзацлары үз көчен югалткан дип танырга;

2.3 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«вәкаләтле оешмалардан төрләр исемлеге бу Нигезләмәнең кушымтасында күрсәтелгән физик затларның керемнәре турында мәгълүматлар.»;

2.6 нчы пунктның өченче абзацында «субсидия» сүзен «торак урын һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләүгә субсидия (алга таба – субсидия)» сүзләренә алыштырырга;

2.8 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.8. Хезмәт ветеранына айлык акчалата түләү билгеләү өчен уртача айлык керем аның айлык акчалата түләү билгеләү турында гариза биргән ай алдыннан алты календарь айга кадәрге соңгы 12 календарь ай өчен (алга таба – исәп-хисап чоры) керемнәре суммасыннан чыгып исәпләнә.»;

2.10 нчы пункт үз көчен югалткан дип танырга;

3.6 нчы пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балага айлык пособие билгеләгәндә гаиләнең җан башына уртача керемен исәпләү тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 ел, 17 декабрь, 542 нче карары белән расланган Балага айлык пособие билгеләгәндә гаиләнең җан башына уртача керемен исәпләү тәртибенең 2.1 нче пунктындагы «к» пунктчасының өченче абзацында һәм 2.2 нче пунктның «в» пунктчасындагы алтынчы абзацында күрсәтелгән, гариза бирүче һәм аның гаилә әгъзаларының керемнәрен раслый торган документлар;»;

3.11 нче пунктта:

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«вәкаләтле оешмалардан балага айлык пособие билгеләү турындагы мәсьәләне хәл иткәндә исәпкә алына торган физик затларның керемнәре турында мәгълүматлар;»;

бишенче һәм сигезенче абзацлар үз көчен югалткан дип танырга;

3.19 нчы пункт үз көчен югалткан дип танырга;

7.2 нче пунктның бишенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

7.3 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«вәкаләтле оешмалардан төрләр исемлеге бу Нигезләмәнең кушымтасында күрсәтелгән физик затларның керемнәре турында мәгълүматлар.»;

9.1 нче пунктның дүртенче һәм җиденче абзацлары үз көчен югалткан дип танырга;

9.2 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«вәкаләтле оешмалардан төрләр исемлеге бу Нигезләмәнең кушымтасында күрсәтелгән керемнәр турында мәгълүматлар.»;

9.8 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9.8. Юл йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү өчен уртача айлык керем юл йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү турында гариза биргән ай булган алты календарь айга кадәрге соңгы 12 календарь ай өчен (алга таба – исәп-хисап чоры) керемнәр суммасыннан чыгып исәпләнә.»;

9.10 нчы пункт үз көчен югалткан дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү турында» 2006 ел, 24 март, 126 нчы

карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 3 июнь, 370 нче; 2009 ел, 6 апрель, 203 нче; 2012 ел, 23 февраль, 153 нче; 2013 ел, 12 март, 157 нче; 2014 ел, 25 август, 611 нче; 2015 ел, 23 сентябрь, 701 нче; 2015 ел, 1 декабрь, 911 нче; 2016 ел, 22 июнь, 425 нче; 2016 ел, 26 декабрь, 998 нче; 2018 ел, 25 декабрь, 1228 нче; 2019 ел, 11 март, 168 нче; 2019 ел, 13 март, 181 нче; 2019 ел, 20 декабрь, 1173 нче; 2020 ел, 2 июнь, 461 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.2 нче пунктның сигезенче һәм тугызынчы абзацлары үз көчен югалткан дип танырга;

$2.2^1$ нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«вәкаләтле оешмалардан төрләр исемлеге бу Нигезләмәнең кушымтасында күрсәтелгән физик затларның керемнәре турында мәгълүматлар.

Гражданнар үз инициативасы белән Үзәк бүлегенә бу пунктта күрсәтелгән мәгълүматлар бирелгән документларны тапшырырга хокуклы.»;

2.3 нче пунктның өченче абзацында «субсидия» сүзен «торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидия (алга таба – субсидия)» сүзләренә алыштырырга;

$2.3^1$ нче пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$2.3^1$. Хезмәт ветеранына субсидия-ташлама билгеләү өчен уртача айлык керем аның субсидия-ташлама билгеләү турында гариза биргән ай алдыннан алты календарь айга кадәрге соңгы 12 календарь ай өчен (алга таба – исәп-хисап чоры) керемнәре суммасыннан чыгып исәпләнә.»;

өченче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге Нигезләмәгә теркәлгән кушымтаның 2 нче пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«I төркем инвалидны (I төркем балачактан инвалидлардан тыш), шулай ук медицина оешмасы бәяләмәсе буенча даими чит кеше каравына мохтаҗ яисә 80 яшькә җиткән өлкәннәрне карауны гамәлгә ашыручы эшләми торган эшкә сәләтле затларга айлык компенсация түләүләре пенсионерның керемнәрендә исәпкә алына.».

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балага айлык пособие билгеләгәндә гаиләнең җан башына уртача керемен исәпләү тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 ел, 17 декабрь, 542 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2016 ел, 10 сентябрь, 625 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 20 декабрь, 959 нчы; 2017 ел, 28 март, 193 нче; 2019 ел, 20 декабрь, 1174 нче; 2020 ел, 17 апрель, 304 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Балага айлык пособие билгеләгәндә гаиләнең

җан башына уртача керемен исәпләү тәртибенә, 4.1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«4.1. Балага айлык түләү билгеләгәндә гаиләнең уртача җан башына кереме гаилә әгъзаларының балага айлык пособие билгеләү турында гариза биргән ай алдыннан алты календарь айга кадәрге соңгы 12 календарь ай өчен (алга таба – исәп-хисап чоры) керемнәре суммасыннан чыгып исәпләнә.».

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшьтән җиде яшькә кадәрге (җиде яшьне кертеп) балага айлык акчалата түләү турында» 2020 ел, 10 апрель, 267 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 10 сентябрь, 823 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Өч яшьтән җиде яшькә кадәрге (җиде яшьне кертеп) балага айлык акчалата түләү бирү тәртибенә һәм шартларына, 3.71 нче пункттагы «3.71» саннарын «$3.7^1$» саннарына алыштырып, үзгәреш кертергә.

5. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшьтән җиде яшькә кадәрге (җиде яшьне кертеп) балага айлык акчалата түләү турында» 2020 ел, 10 апрель, 267 нче карары белән расланган Өч яшьтән җиде яшькә кадәрге (җиде яшьне кертеп) балага айлык акчалата түләү бирү тәртибенә һәм шартларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 10 сентябрь, 823 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче пунктта:

дүртенче абзацта «3.71» саннарын «$3.7^1$» саннарына алыштырырга;

бишенче абзацта «3.71» саннарын «$3.7^1$» саннарына алыштырырга;

2 нче пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«бу карарның 1 нче пунктындагы дүртенче һәм бишенче абзацлары 2020 елның 30 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла һәм 2020 елның 31 декабренә кадәр (31 декабрьне кертеп) гамәлдә була;».

6. Җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары карарларына 2021 елның 1 гыйнварыннан уртача җан башына кереме гаилә әгъзаларының өстәмә компенсация билгеләү турында гариза биргән ай алдыннан алты календарь айга кадәрге соңгы 12 календарь ай өчен кереме суммасыннан чыгып 20 мең сумга кадәр булган гаиләләргә мәктәпкәчә белем бирүче мәгариф программаларын тормышка ашыручы белем бирү оешмаларында балаларны караштыру һәм карау өчен ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) алына торган түләүнең бер өлешенә өстәмә компенсация билгеләгәндә гаиләнең уртача җан башына керемен исәпләүне күздә тота торган үзгәрешләрне кертүне тәкъдим итәргә.

7. Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына бу карарны тормышка ашыруны тәэмин итү өчен «Халыкның социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасын эшләп бетерүне тәэмин итәргә.

8. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

бу карар (бу пункт белән үз көченә керүнең башка вакытлары билгеләнгән нигезләмәләрдән тыш) рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә;

бу карарның 1 нче пунктындагы беренче, тугызынчы – унбишенче абзацлары, 3 пункты 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә;

бу карарның 1 нче пунктындагы икенче – сигезенче, уналтынчы – егерме дүртенче абзацлары, 2 нче пункты 2021 елның 1 апреленнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин